**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА СТЕПНООЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423009, с. Степное Озеро, ул. Школьная, дом 23, телефон:8(84345) 4-63-34

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИКҮЛЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

423009, Бикүле авылы, Мәктәп ур., 23 йорт, телефон:8(84345) 4-63-34

ОГРН 1021605352438,ОКПО 04312541, ОКАТО 92246880000,
ИНН/ КПП 1632001635/163201001,ОКТМО 92646480


---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 30» ноябрь 2019 ел** **№ 4**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Илюткино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 13 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка М. Горький урамы буенча 13нче номерлы йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Илюткино авылында М. Горький урамы буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2019 елның 13 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Совет урамы буенча 14нче номерлы йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Илюткино авылында Совет урамы, Клуб урамы буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. 2019 елның 15 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Җиңү урамы буенча 6нчы номерлы йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Илюткино авылында Җиңү урамында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.
4. Гражданнар җыенын уздыру өчен Илюткино авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибе территориаль билге буенча башкарырга.

5. Гражданнар жыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлегенең Илюткино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1). Илюткино авылы чикләрендәге юлларны ремонтлау (юлларга вак таш сатып алу, ташу, җәю, транспорт хезмәтләре)

2). Буа территориясен төзекләндерү.

«ӘЙЕ» «ЮК».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына http://nurlat.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Бикүле авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Садыков